| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.12.2025 № 1527

2026 елга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларының хосусый сак оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда куркынычлылыкның өченче категориясенә кертелгән объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләрнең норматив бәясен җирле бюджет акчалары исәбеннән арттыру турында

«Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 06 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы объектларының (территорияләренең) һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы эшчәнлеге өлкәсенә караган объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы сакланышына таләпләрне һәм бу объектларның (территорияләрнең) иминлек паспорты рәвешләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 02 августындагы 1006 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) хосусый сак оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр бәясе нормативларын раслау һәм 12 сәгатьлек эш режимындагы сак постлары санын билгеләү турында»2021 елның 23 ноябрендәге 1114 номерлы карарына таянып, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) хосусый саклау оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләр бәясе нормативларын билгеләү тәртибе турында методик тәкъдимнәрне раслау хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 23 ноябрендәге 1112 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларының бер сәгать саклау бәясе күрсәткечләрен мониторинглау нигезендә куркынычлыкның өченче категориясенә кертелгән объектларын террорчылыкка каршы яклауны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының җирле бюджеты акчалары исәбеннән 2026 елга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең)

хосусый саклау оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле саклау хезмәтләренең бер пост-сәгатенең норматив бәясен 220,0 сумга кадәр арттырырга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәгариф оешмаларының хәвефлелекнең өченче категориясенә кертелгән объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле саклау хезмәтләрен сатып алуга әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән норматив нигезендә өстәмә финанслау тәэмин итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларының хәвефлелекнең өченче категориясенә кертелгән объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле саклау хезмәтләрен әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән норматив нигезендә сатып алырга.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларының 2025 елга хосусый сак оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда куркынычлылыкның өченче категориясенә кертелгән объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләрнең норматив бәясен җирле бюджет акчалары исәбеннән арттыру турында» 28.01.2025 ел, № 86 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин